# *Җир кадере*

***Җир белән бәйләнешле һөнәрне йөрәк кушуы буенча сайлаучы кешеләр сирәктер ул. Моның өчен җирне чын күңелдән яратырга, аны аңлый белергә, аңа хөрмәт белән карарга кирәк бит. “Кама”күмәк хуҗалыгы рәисе Ибраһим Миндар улы Галимов - әнә шундыйларның берсе.***

Аваыл хуҗалыгы институтының агрономия бүлеген тәмамлап, юллама буенча Тукай мсемендәге колхозга эшкә җибәрелгән яшь белгечне тиздән “Кама” хуҗалыгына рзис итеп сайлыйлар. Бу 1983 ел була.

Яңа эшне башлавы 1әрвакыт авыр инде,- дип искә ала Ибраһим Миндарович ул чакларны. – биш авылны үзенә берләштергән хуҗалыкта нибары 5-6 комбайн бар иде.

Җитәкченең белемле, тәҗрибәле кадрлар туплавы, эшне дөрес оештыра белүе тиздән уңай нәтиҗәләр бирә: 1985 елда комбайннар паркында 15, ә 1987 елда инде 26 “кыр корабы” исәпләнә. Урып-җыю эшләре дә ул вакытларда 15-16 көндә төгәлләнә.

Кызганычка каршы, заманаларның кире якка үзгәрүе, төрле реформалар, кырыс базар шартлары авыл хуҗалыгының хәлен мөшкелләндерә. Машина-трактор паркы искерә, аны яңартырга мөмкинлек булмый. Моңа шулай ук ягулык-майлау материалларына бәяләрнең үсүе, җитештерелгән продукциянең үзкыйммәте түбән булуы да сәбәпче.

Иске техника еш ватыла, бу, үз чиратында, кыр эшләрен вакытында төгәлләргә мөмкинлек бирми. Кайвакытһава торышы да игенчегә кулай килми. Бу турыда И.Галимовның эш көндәлегендә кызыклы язмалар бар: “22 июльдә борчак чабуга, 25е – аны сугуга төштек”. Аннан соң бер ай һәм өч көн буе көндәлектәге язулар үзгәрми: “Бүген тагын яңгыр яуды...”. “8 август: ниһаять көн аязды”.

Димәк, урып-җыю эшләре нәкъ бер айга тоткарланган. Шуңа да карамастан, камалылар уракны районда беренчеләрдән булып тәмамладылар. Уңыш – районда иң югарысы: гектарыннан 34,4 центнер. Хуҗалык уңганнары дәүләткә товар кредитын шулай ук иң беренчеләрдән булып түләделәр.

-Бу - механизаторлар, тракторчылар, шоферларның фидакарь хезмәт нәтиҗәсе, - ди Ибраһим Миндарович.- Иртә таңнан караңгы төнгә кадәр басуда булдылар алар. Форсаттан файдаланып, механизаторлар Н.Азин, Р.Камалетдинов, тракторчылар Р.мусчин, Ш.Шәрифуллин, К.Идаев, шоферлар Р.Галимсов, Р.Халиков, Н.Ивановларга зур рәхмәтләремне белдерәм.

Быел хуҗалыкка лизинг буенча “Дон” комбайны, ДТ-75 тракторы, бушлай “КамАЗ” машинасы кайтарылган. Шулай ук үз көчләре белән чәчкеч, тагын кайбер авыл хуҗалыгы техникасы да алганнар.

Бу, әлбәттә, кыр эшләрендә зур ярдәм. Менң әле хәзер дә, кар көз булуга карамастан, басуларда трактор гөрелтеләре тынмый. Туңга сөрү инде тәмамланды. Хәзер механизаторлар 350 гектар мәйданда чәчелгән уҗым культураларын ашламалар белән тукландыралар. Аннан техниканы

ремонтлау эшләре башланыр. Игенченең мәшәкате бетми бит ул: берсен-берсе алыштырып кына тора.
Бүген – Уңыш бәйрәме. Башкарылган эшкә йомгак ясаганда “Кама” хуҗалыгы рәисе Ибраһим Миндарович Галимовка кызарырга туры килмәс. Аның уңышларының серенә үзе белән әңгәмәдә төшендем:” минем колхозчыларым, минем басуларым, Минем җирем” дип сөйләде ул. Ә уңышлыкларның сере менә шуларның барысының да кадерен белүдә икән бит.

“Менделеев яңалыклары” 6 октябрь , 2000 ел.
Р.Мирзаянова





